# 1

Хөрмәт Жилплощадкадагы тулай торакта яши. Соңгы араларда ул Восстание урамына күчәргә дә ниятләгән иде. Чөнки трестның спорт залы шул тирәдә. Өстәвенә ул туганнан туган абыйсы белән еш аралаша, аларның спорт базасында да булганы бар. Аннары сирәк-мирәк авыл хуҗалыгы һәм ветеринария институтларына баргалый. Аларда татарча көрәш секцияләре эшли, тренерлары бик шәп. Хөрмәт ул остазлардан күп нәрсәгә өйрәнде. Ләкин комендант та, тәрбияче дә, ялынып-ялварып дигәндәй, аның китмәвен үтенделәр. Чөнки ул — үзе кебек үрнәк, актив егетләрдән торган сугышчан комсомол дружинасының җитәкчесе. Ә биредә яшәүчеләрнең тәртип ягы чамалы — узынып китүләр, тукмашулар еш кабатлана. Гәрчә теш кайрап йөрүчеләр булса да, күпчелеге солдат шулпасы эчкән дружиначылар тулай торакны үз кулларында нык тоталар. Укуын исәпкә алып (Хөрмәт быел физкультура институтына читтән торып укырга керде), аңа аерым бүлмә бирделәр. Шуларны уйлап китмәскә булды: әле бу тулай торак подвалында да егетләрне көрәш серләренә өйрәтә бит ул.

Хөрмәт уникенче автобустан төште дә, юл аркылы чыккач, урам чатында туктап калды һәм үзалдына елмаеп куйды: шәһәр уртасында диярлек атлы арба тора, ике авыл кешесе, ирле-хатынлы булсалар кирәк, бәрәңге саталар.

Абзый колакчынын артка каерып бәйләгән бүрек кигән, өстендә бишмәт, авызына папирос капкан. Хатыны да янында басып тора: башында ак яулык, өстендә кара жикет, аягында резина боты. Алар, терсәкләре белән арба үрәчәсенә таянып, тыйнак кына сөйләшәләр.

Җирдә ике-өч капчык, берсенең өсте ачык, янәшәдә чүмәләкәй бәрәңге тулы ак чиләк.

Ат башына солылы капчык бәйләнгән. Бахбай, башын ия төшеп, солы каба, аннан башын күтәребрәк ашый,

берөзлексез колакларын кыймылдата: әле турайта, әле як-якка җәя. Ат яңадан башын ия дә капчыкны селки, күрәсең, солы өскә күтәрелә...

Хөрмәт, бөтен дөньясын онытып, читкәрәк китеп карап тора — күңеленә якын гади авыл кешеләрен күзәтә. Гәрчә үтеп-сүтеп йөрүче кешеләр очраса да, бәрәңге алучы юк. Ә, менә бер хатын бәрәңге алды.

Хөрмәт кибеткә барып килде дә тагын читтән генә күзәтә башлады. Үз туганнарыдай якын тоелган бәрәңге сатучылар, арба кырына сөялеп, колбаса белән булки ашап торалар. Баягы капчык сатылып беткән, икенчесен башлаганнар. Атның да солысы азайган, ахры, як-якка караштыра, арт аякларын авыштырып, гәүдәсенең авырлыгын әле бер, әле икенче аягына төшерә; ашаганда, капчыгы селкенеп куя.

Күп тә үтмәде, сатучылар янына өстенә плащ кигән эшләпәле ир-ат килеп басты. Ул ике бармагы белән генә бер бәрәңге алып карады. Бәрәңгене чиләккә ташлагач, бармакларыннан җир тузанын кагып, кулын кесәсенә тыкты, тегеләр белән сатулашырга кереште. Хатын ризыкны, җыеп, төреп, куенына — жикет эченә тыгып куйды. Шәһәр кешесе, капчыкны ачып, янә бәрәңгене карады, ләкин кулын тидермәде. Кыйбатсындымы — сатып алмады, кулларын кесәсенә тыгып китеп барды.

Хөрмәтнең ачуы чыкты. Тегеңә әйтәсе килде: «Агайне, син ул бәрәңгенең ничек үскәнен беләсеңме соң? Аның әнә шул ирле-хатынлы авыл кешеләренең сөялле, яргаланган, каралган, бармаклары кәкрәеп торган, әмма эш сөючән куллары аша ничә тапкыр үткәнен беләсеңме? Аны үстерергә күпме хезмәт киткәнен, тир түгелгәнен беләсеңме? Кыйбат, имеш. Хет бер тапкыр гына үстереп кара! Аннан белерсең кадерен... Хәер, син дә кайдадыр эшлисеңдер, әрәмтамак түгелсеңдер. Ләкин кыйбатсынма, ал. Авыл кешесе ачкүз түгел — беркайчан да бәянең артыгын куймый, үлчәгәндә дә бер-ике бәрәңгене өстәп сала әле...»

Сатучы ат авызыннан капчыкны алды да күтәребрәк бәйләп куйды.

— Аша, малкай, — диде һәм тәмәке кабызды. Абзыйның атын яратуы, аны ач тотмавы — үзенчә сыйлавы — әллә каян күренеп тора. Юкка гына халкыбыз, азыклы ат арымас, димәгәндер, әле аларның кире кайтасы да бар бит.

Хөрмәт күзәтүен дәвам итте: бер карчык, аннары сумка тоткан ике хатын, рәхмәтләр әйтә-әйтә, бәрәңге алып киттеләр. Ә егет, авылын, анда калган әнисен сагынып, Казан уртасына килеп кергән атлы арбадан күзен алалмыйча, байтак вакыт карап торды. Аннары, кинәт нәрсәдер исенә төшкәндәй, тиз-тиз генә китеп барды.

...Хөрмәт җиңелчә генә шакыды да, эчтән җавап биргәннәрен дә көтмичә, бүлмә ишеген ачты.

Өстәл янында эчке күлмәктән генә торган Мәнвия нидер үтүкли иде.

— Ой!.. — дип кычкырып җибәрде ул. — Керми тор. Мин хәзер!

Хөрмәт ишекне япты, бер-ике адым артка чикте. Озак та үтмәде, өстенә халат киеп алган кыз үзе бүлмә ишеген киң итеп ачты һәм аны чакырды.

— Кер.

Ул кул биреп исәнләште дә Хөрмәтне кочаклап алды. Егет тә, кулындагы әйберләрен урындыкка куеп, аны кочты, иреннәреннән суырып үпте.

Мәнвиянең сагынуы шулхәтле көчле иде, ул егетеннән күзен алалмады, кояштан да болайрак балкыды. Төптән юан, уртача буйлы, тыгыз тәнле бу егет Мәнвияне бөтенләй сихерләгән, дөресрәге, кыз үзе сихерләнгән иде. Кемнәр өчендер кысыграк кечкенә күзле, җәлпәгрәк борынлы Хөрмәт, бәлки, әллә ни искитәрлек егет тә түгелдер. Ә Мәнвиягә аның көчле, кыска бармаклы таза кулларына хәтле якын, тансык иде. Ул егетнең иреннәрен очлайтыбрак бөтен бите белән елмаюына хәтле сагынган иде. Мәнвия яхшы белә: Хөрмәтнең һәр кылган гамәле ихлас. Бәлки, ул шуның белән кызның күңелен яулагандыр да әле.

Мәнвия, озак карап торуыннан оялып, Хөрмәткә урын тәкъдим итте һәм сораштыра башлады:

— Кайчан кайттың?.. Ничек ял иттең?..

Егет үзе җавап бирде, ә үзе күзләрен кыздан алалмады. Кара чәчләрен, уртадан юл ярып, баш артына өеп-төйнәп куйган, киң маңгайлы, кыйгач кашлы Мәнвия табигый матурлыгы белән егетне һәрчак сокландыра иде. Бүген аеруча. Бераздан егет әйберләрен, урындыктан алып, өстәлгә куйды.

— Борын кычыткан иде, — диде Мәнвия, алма, конфетларга күз төшереп алгач көлеп. — Чишен.

Эш шунда: Хөрмәт чираттагы ялда булып кайткан иде. Ул әүвәл авылында кышка утын хәстәрләде, каралты-кура, йорт-җирне караштырды. Аннары, профсоюздан туристик юллама алып, тресттан җыелган төркем белән ике-өч көнгә Киевка барып кайтты.

Хөрмәт плащын, кашнесын һәм козырёклы фуражкасын чөйгә элде. Кара костюмының төймәләренә кул тидереп алды, галстугын бушатыбрак куйды, учы белән җитү чәчен сыпырды. Мәнвия аның күлмәгенә игътибар итте — яңа булса кирәк, һәрхәлдә, моңарчы күргәне юк иде.

Сәяхәттән ияреп кайткан открыткалар, значоклар, карточкалар карап утырганда, күрше бүлмәдән кызлар кереп-чыгып йөрде — идән юалар икән.

Аннары Мәнвиянең абыйсы (әнисенең энесе) керде, сеңлесен авырый дип белгән. Бик күңелле кеше икән, бераз «төшереп» тә алган. Мәнвиянең хәлен сорашты, Хөрмәт белән дә гәпләште. Хатыны хастаханәдә икән. Бер ярты кызыл шәраб һәм йөзем кыстырып кергән.

Ул арада Мәнвия чәй әзерләде. Абзый, яртыны ачып, бер стакан җибәрде, Хөрмәт кабып кына куйды, Мәнвия бөтенләй баш тартты. Абзый киткәч, бу бүлмәдә яшәүче Рәҗия кайтып керде.

Уртача буйлы, түгәрәк йөзле, коңгырт чәчле Рәҗия әңгәмәдәше белән ачык йөз күрсәтеп сөйләшә, сәхнәдә декламация сөйләгән балалар кебек, һәр сүзен җиренә җиткереп, аермачык итеп әйтә. Сөйләшкәндә, тулышып торган битенең яңак мускулларына һәм дугайланып килгән матур кашларына хәтле уйнаклап тора. Урицкий исемендәге мәдәният сараеның халык театрына йөрүче, кеше белән һәрчак елмаеп сөйләшүче бу кызның әйтерсең лә бер кайгысы да юк.

Ә чынында алай түгел, аның да эчендә ут уйнаган чаклары була. Ул, Хөрмәт белән исәнләшкәч, кулындагы сумкасыннан тумбочкасына әйберләр бушата башлады һәм Мәнвиягә сорау бирде:

— Минем хайван күренмәдеме?

— Юк.

Сүз егете турында бара, ахры, кыз әле һаман тынычлана алмый:

— Подумаешь, вакыты юк. Ул инженер була, ә мин — эшче.

— Ярар инде, — диде Мәнвия, аны юатып.

— Нәрсә булды? — дип сорады Хөрмәт, ул үзе теге егетне бер тапкыр гына күреп калган иде.

Мәнвия аңлатып бирде. Рәҗияне егете ташлаган икән. «Мин, конечно, гафу үтенәм, но вакыт тар, эш, уку, экзаменнар, яңадан килеп йөри алмам», — дип әйтеп әйткән, ди. Рәҗия һаман оныта алмый, еш кына балавыз да сыгып ала икән.

Хөрмәт тә кызны тынычландырырга теләде:

— Аптырама, яңаны табарбыз.

— Үзем дә төшеп калганнардан түгел әле, — диде кыз һәм көлеп җибәрде. — Казанга килгәч, беренче тапкыр свиданиегә бардым. Юри киендем: өстә ак кофта һәм кара трико. Мин, кинога барабыз, дигәч, егет аптырады. Ярар, мин әйтәм, икенче көнне барырбыз. Ул көнне футболка, яшел итәк һәм тапочка киеп чыктым, юрамалый гына, ни әйтер икән дип... Икенче юлы тагын бер мәхлук бәйләнде. Мин колхозга китәсе идем. Кайткач, егет, син Рәҗияме, ди. Юк, мин әйтәм. Ул кат-кат сорый. Отшибла мин анысын да. Әллә нинди сөйкемсезләр иде алар икесе дә... Ә бу, хайван, бик ошаган иде, әллә ничек менә мәхәббәтле иде ул...

Хөрмәт көлмичә түзә алмады. Рәҗия үзе дә ап-ак тешләрен күрсәтеп елмая, һәм аның матур йөзе гамьсез кыяфәт алган. Гүя ул, күңелендәге рәнҗешне белгертмәс өчен, тышка чыгармас өчен, битлек кия иде.

— Безнең коридорда төнлә әллә кеше, әллә җен йөри, — дип көлде Рәҗия. — Син килмисеңдер бит?

— Юк, — диде Хөрмәт, пальтосын салып, күлмәкчән генә калган Рәҗиянең зифа буена сокланып. «Бу сылуның нәрсәсе ошамагандыр ул «хайван»га?» — дип, эчтән генә Рәҗия сүзе белән теге егетне сүгеп ташлады.

Мәнвия Рәҗияне, күчтәнәчләр белән чәй эчик, дип, өстәлгә утыртты, ә үзе Хөрмәткә «Здоровье» һәм «Азат хатын» журналларын бирде.

Соңгысына ишарәләп:

— Анда «Коръән серләре»ннән өзек бар, — диде. — Хатын-кызлар, ир-атлар турында, бик кызык.

— Ә мин Айтматовның «Җәмилә»сен укыдым, — диде Рәҗия, тоткалы, бизәкле чынаяктан чәй уртлап. — Талант шулдыр инде ул: кечкенә генә повестьта кешене үзенә җәлеп итәрлек, искитәрлек итеп гасырлар буена язылган